ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 495-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 495-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2218-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясының 1 өлешенә (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлектәге $5^1$ пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«$5^1$) хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**"Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 120-ТРЗ номерлы Закон) федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнгән.

«Хайваннарга карата җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 377-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы белән «Хайваннарга карата җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законга хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга салуга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде.

Үзгәрешләр, аерым алганда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының әлеге өлкәдәге вәкаләтләренә кагыла. Мәисалга, әлеге органнарның вәкаләтләренә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру кертелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге вәкаләтләре 120-ТРЗ номерлы Законның 4 статьясындагы 1 өлешенә беркетелгән.

Әлеге закон проектына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру вәкаләтләрен бирү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.